СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.13, д. Нижняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл жирлеге башлыгы карары**

**25сентябрь 2024 ел** **N 7**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2024 елның 5 апрелендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 5 апрелендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыенының беренче этабын Югары Курса авылы Мәктәп урамы, 20 йорт адресы буенча 2024 елның 08 октяберендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 5 апрелендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыенының икенче этабын Югары Курса авылы Мәктәп урамы, 20 йорт адресы буенча 2024 елның 08 октяберендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Мәктәп урамы халкы

2 нче этап: А.Алиш урамы, Яр буе урамы, К. Тинчурина урамы халкы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2024 елның 05 апрелендәге 2 номерлы карарга үзгәрешләр кертү белән килешәсезме,» Россия

Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга обелиск кую, төзекләндерү) «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар сатып алу, Югары Курса авылының су җыю манарасы территориясендә койма урнаштыру)» на?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Югары Курса авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 5 апрелендәге 2 номерлы номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина